| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы<br>Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек<br>министрлыгы | Татарстан Республикасы<br>Яшьләр эшләре<br>министрлыгы |
| 2025 ел, 27 октябрь<br>№ 291/2 | 2025 ел, 27 октябрь<br>№ 364 |

Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының яшь хезмәткәрләре арасында «Һөнәре буенча иң яхшы» республика һөнәри осталык конкурсы турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 5 мартындагы 158 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Авыл яшьләре» төбәк проектын гамәлгә ашыру максатларында:

1. Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының яшь хезмәткәрләре арасында «Һөнәре буенча иң яхшы» республика һөнәри осталык конкурсын әзерләү һәм уздыру буенча Оештыру комитеты төзергә һәм әлеге Боерыкның 1нче кушымтасы нигезендә аның составын расларга.

2. Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының яшь хезмәткәрләре арасында «Һөнәре буенча иң яхшы» республика һөнәри осталык конкурсы турындагы нигезләмәне әлеге Боерыкка 2нче кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләргә.

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры урынбасары -<br>Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы<br>һәм азык-төлек министры | Татарстан Республикасы<br>Яшьләр эшләре министры |
| ______________________М.А. Җәббаров | ___________________А.Р. Кадыйров |

Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы һәм
азык-төлек министрлыгының
2025 елның 27 октябре
291/2 номерлы
һәм
Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре
министрлыгының
2025 елның 27 октябре
364 номерлы
уртак боерыгына

1нче кушымта

**Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының яшь хезмәткәрләре арасында «Һөнәре буенча иң яхшы» республика һөнәри осталык конкурсының оештыру комитеты**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Мәхмутов Марсель Азат улы | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары, Оештыру комитеты рәисе |
| Галиева-Мостафина Софья Альфред кызы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрының беренче урынбасары, Оештыру комитеты рәисе урынбасары |
| Заһидуллина Миләүшә Мөдәрис кызы | «Татарстан Республикасы Аграр яшьләр берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе, Оештыру комитеты секретаре (килешү буенча) |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Гамиров Алмаз Гаяз улы | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының фән, мәгариф һәм инновацион технологияләр бүлеге башлыгы |
| Вавилова Марина Александровна | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының территорияләр белән эшләү һәм яшьләр сәясәте инфраструктурасын үстерү бүлеге башлыгы |

| | |
|---|---|
| Грахова<br>Александра Юрьевна | «Татарстан Республикасы Аграр яшьләр берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы башкарма директоры (килешү буенча) |
| Вәлиев<br>Айрат Рәсим улы | «Казан дәүләт аграр университеты» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең беренче проректоры (килешү буенча) |

Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы һәм
азык-төлек министрлыгының
2025 елның 27 октябре
291/2-пр номерлы
һәм
Татарстан Республикасы
Яшьләр эшләре
министрлыгының
2025 елның 27 октябре
364 номерлы
уртак боерыгына

2нче кушымта

**Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының яшь хезмәткәрләре арасында «Һөнәре буенча иң яхшы» республика һөнәри осталык конкурсы турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 5 мартындагы 158 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Авыл яшьләре» төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының яшь хезмәткәрләре арасында «Һөнәре буенча иң яхшы» республика һөнәри осталык конкурсын (алга таба - Конкурс) оештыру һәм уздыру тәртибен билгели.

1.2. Конкурсны оештыручылар - Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы һәм «Татарстан Республикасы Аграр яшьләр берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы (килешү буенча).

1.3. Конкурс Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының яшь хезмәткәрләренең һөнәри осталыгын арттыру һәм авыл хуҗалыгы һөнәрләренең абруен күтәрү, алдынгы тәҗрибәне тарату, яшьләрне агросәнәгать комплексы оешмаларына эшкә җәлеп итүдә ярдәм итү максатларында ел саен оештырыла һәм үткәрелә.

1.4. Конкурсның бурычлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының иң яхшы яшь хезмәткәрләрен ачыклау, аларга ярдәм итү һәм аларны бүләкләү;

уңай җәмәгатьчелек фикерен булдыру, авыл хуҗалыгы тармагы һөнәрләрен популярлаштыру;

хезмәт казанышларын популярлаштыру, алдынгы тәҗрибәне тарату;

авыл хуҗалыгы тармагы хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрүгә һәм хезмәт базарында конкурентлыкка сәләтлелеген арттыруга ярдәм итү, һөнәри үсеш, шулай ук тәҗрибә алмашу өчен мөмкинлекләр тудыру;

ярышу мохитендә конкуренция шартларында Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы яшь хезмәткәрләренең югары квалификациясен, белемнәрен һәм осталыкларын күрсәтү.

1.5. Конкурсны уздыруның төп принциплары: хәбәрдарлык, процедураларның һәркем өчен ачык, файдалана алырлык булуы һәм Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының яшь хезмәткәрләренә анда катнашу өчен тигез мөмкинлекләр тәэмин итү.

## II. Конкурста катнашу шартлары

2.1. Конкурста катнашуга Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының 18 яшьтән 35 яшькә кадәрге, югары яисә урта һөнәри белемле, эш стажы бер елдан да ким булмаган хезмәткәрләре (алга таба – катнашучы) кертелә.

Конкурста Татарстан Республикасында теркәлгән, барлык милек һәм оештыру-хокукый рәвешләрендәге агросәнәгать комплексы оешмаларының хезмәткәрләре катнаша ала.

2.2. Конкурсны уздыру турында белдерү Конкурсны оештыручылар тарафыннан Конкурска гаризалар кабул итү башлану көненә кадәр ун календарь көненнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (https://agro.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының (https://minmol.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан Республикасы Аграр яшьләр берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасының (алга таба – «ТР Аграр яшьләр берләшмәсе» ТИО) (https://amo-rt.tatarstan.ru/) рәсми сайтларында урнаштырыла, анда Конкурсны уздыру сроклары, Конкурсның аерым процедураларын үтәү сроклары турында мәгълүмат бар.

Конкурста катнашу өчен Конкурсны уздыру турында әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән белдерү ителгән көннән алып 30 календарь көн эчендә «Татарстан Республикасы Аграр яшьләр берләшмәсе»ТИО кушымтасында электрон гариза (алга таба – гариза) тутырырга кирәк:

**App Store өчен**

https://apps.apple.com/ru/app/%D0%B0%D0%BC%D0%BE-%D1%80%D1%82/id6737065706

**Android өчен**

https://play.google.com/store/apps/details?id=ru.smartpetrol.amort

2.3. Гаризага электрон документлар һәм (яисә) документның кәгазь чыганагын сканерлау юлы белән булдырылган түбәндәге документларның электрон рәвешләре беркетелә:

шәхесне таныклаучы документ;

салым түләүченең идентификация номерын бирү турында таныклык (ИНН);

мәҗбүри пенсия иминияте системасында иминләштерелгән затның индивидуаль шәхси счетының иминият номеры булган дәүләт пенсия иминиятенең иминият таныклыгы (СНИЛС);

хезмәт кенәгәсе яисә хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр;

белеме турындагы документ;

Россия кредит оешмасында ачылган счет реквизитлары турында белешмәләр булган документ;

законнарда каралган таләпләрне үз эченә алган шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык;

законнарда каралган таләпләрне үз эченә алган, тарату өчен субъект тарафыннан рөхсәт ителгән шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалык.

2.4. Конкурста катнашуга гариза җибәрү мөрәҗәгать итүченең әлеге Нигезләмәнең барлык шартлары белән тулысынча риза булуын аңлата.

2.5. Конкурста катнашуга гаризаларны кире кагу өчен түбәндәгеләр нигез була:

Конкурста катнашуга гариза вакытында тапшырылмау;

гаризада тулы булмаган белешмәләр булу;

әлеге Нигезләмәнең 2.3 пунктында күрсәтелгән документлар булмау һәм (яисә) документлар комплекты тулы булмау;

мөрәҗәгать итүченең «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты статусы булу.

2.6. Әлеге Нигезләмәнең 2.5 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта, мөрәҗәгать итүчеләр Конкурста катнашуга кертеләләр һәм Конкурста катнашучылар дип танылалар.

2.7. Конкурста катнашучы, конкурста катнашуга бәйле мәсьәләләр буенча консультацияләр, аңлатмалар һәм техник ярдәм сорап, Оештыру комитетына мөрәҗәгать итә ала.

2.8. Узган елгы Конкурста 1нче урынны алган җиңүчеләр агымдагы елда Конкурста катнашуга кертелмиләр.

2.9. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (Конкурс уздырыла торган урынга бару һәм кире кайту, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һәм башкалар) Конкурста катнашучыларның үз акчалары исәбеннән башкарыла. Конкурста катнашучыларның тору урыны һәм тукланулары өчен түләү кабул итүче як исәбеннән түләнә.

## III. Конкурс этаплары һәм номинацияләре

3.1. Конкурс ике этапта уздырыла:

I этап - теоретик өлеш;

II этап - практик өлеш.

3.2. Теоретик өлеш тестлаштыру рәвешендә уздырыла, ул тармак үзенчәлекләрен белүгә сораулардан торучы сораштыру кәгазьләрен тутыруны күздә тота. Сораулар саны - 50. Тестны үтү вакыты - 60 минут.

Практик өлеш махсус җиһазландырылган эш урыннарында, шулай ук һөнәри (эшлекле) уен, әңгәмә рәвешендә уздырылырга мөмкин һәм катнашучының күнекмәләрен, аның квалификациясен, эш технологиясен үтәвен, хезмәтне саклау нормаларын һәм кагыйдәләрен үтәвен, алдынгы хезмәт алымнарын һәм ысулларын

белүен, эшләр башкарганда сыйфатка үз контролен гамәлгә ашыра белүен, һөнәри этиканы үтәвен бәяләргә мөмкинлек бирә.

Практик өлешнең биремен үтәүгә вакыт нормативы 30 минуттан артмый.

3.3. Конкурс номинацияләре:

«Иң яхшы инженер-механик»;

«Иң яхшы агроном»;

«Иң яхшы бухгалтер-икътисадчы»;

«Иң яхшы ветеринария табибы»;

«Иң яхшы зоотехник»;

«Иң яхшы механизатор»;

«Иң яхшы машина белән сыер саву операторы»;

«Иң яхшы терлек үрчетү технологы»;

«Иң яхшы азык-төлек җитештерү технологы».

## IV. Конкурсны оештыру һәм уздыру тәртибе

4.1. Конкурсны әзерләүгә һәм уздыруга гомуми җитәкчелекне Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының яшь хезмәткәрләре арасында «Һөнәре буенча иң яхшы» республика һөнәри осталык конкурсын оештыру комитеты (алга таба – Оештыру комитеты) башкара, аның составы Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының уртак боерыгы белән раслана.

4.2. Оештыру комитетына Оештыру комитеты рәисе, рәис урынбасары, җаваплы секретарь һәм башка әгъзалар керә.

4.3. Оештыру комитеты рәисе Оештыру комитеты эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә, Оештыру комитеты эшен оештыра, Оештыру комитеты утырышын үткәрү вакытын һәм урынын билгели, Оештыру комитеты әгъзаларының тавыш бирүенә йомгаклар ясый.

4.4. Оештыру комитеты рәисе булмаганда, аның вазыйфаларын аның кушуы буенча Оештыру комитеты рәисе урынбасары яисә Оештыру комитеты әгъзаларының берсе башкара.

4.5. Оештыру комитетының җаваплы секретаре утырышның көн тәртибен төзи һәм Оештыру комитеты материалларын әзерләүне оештыра, утырыш датасына кадәр өч көннән дә соңга калмыйча Оештыру комитеты әгъзаларына булачак утырыш турында хәбәр итә.

4.6. Оештыру комитеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә::

Конкурсны әзерләү һәм уздыру эшләрен оештыру һәм координацияләү;

Конкурсны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле документацияне әзерләү;

Конкурсны оештыру һәм уздыру турында мәгълүмат биреп тору;

Конкурста катнашуга гаризаларны кабул итү, карау, кире кагу;

Конкурста катнашучылар исемлеген раслау;

Конкурсның теоретик, практик өлешләрен уздыру датасын һәм вакытын билгеләү;

Конкурс этапларын уздыру сроклары турында катнашучыларга хәбәр итү;

Конкурста катнашучыларга консультатив һәм методик ярдәм күрсәтү;

Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының яшь хезмәткәрләре арасында «Һөнәре буенча иң яхшы» республика һөнәри осталык конкурсының Эксперт советы (алга таба – Эксперт советы) составын төзү һәм раслау;

җиңүчеләрне, призерларны билгеләү, Конкурска йомгаклар ясау;

җиңүчеләрне һәм призерларны бүләкләү;

Конкурсны оештыруга һәм уздыруга бәйле башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

4.7. Оештыру комитеты утырышлары кирәк булган саен чакырыла.

4.8. Оештыру комитеты утырышларын көндезге яисә дистанцион форматта уздыру рөхсәт ителә.

4.9. Оештыру комитеты тарафыннан үз компетенциясе кысаларында кабул ителә торган карарларны Конкурсны оештыруда һәм уздыруда катнашкан барлык катнашучылар һәм затлар үтәргә тиеш.

4.10. Оештыру комитеты утырышлары, әгәр аларда Оештыру комитеты әгъзаларының гомуми санынннан кимендә 50 проценты катнашса, вәкаләтле була.

4.11. Оештыру комитеты карарлары тиешле беркетмә итеп рәсмиләштерелә, ул Оештыру комитеты утырышында рәислек итүче тарафыннан имзалана.

## V. Эксперт советы. Бәяләүне уздыру тәртибе

5.1. Эксперт советы - Конкурс биремнәрен, аларны бәяләү критерийларын эшләүдә катнашу, Конкурсның барлык этапларында катнашучылар үтәгән конкурс биремнәрен квалификацияле бәяләүне тәэмин итү өчен төзелгән коллегиаль орган.

Эксперт советы составы «Казан дәүләт аграр университеты» югары һөнәри белем бирү ФДБМУнең педагогик составы вәкилләреннән төзелә һәм Оештыру комитеты утырышында раслана.

5.2. Эксперт советы:

һәр номинация буенча Конкурсның теоретик сорауларын һәм практик биремнәрен эшли;

Конкурс биремнәрен үтәү алдыннан хезмәтне саклау буенча инструктаж үткәрә;

Конкурста катнашучыларга биремнәрнең эчтәлеген, аларны үтәү тәртибен, баллар исәпләү шартларын аңлата, биремнәрнең башлану вакытын һәм аларның тәмамлану вакытын билгели;

Конкурста катнашучыларның конкурс биремнәрен башкару шартларын үтәүләрен тикшереп тора;

Конкурста катнашучыларның конкурс биремнәрен үтәүләрен бәяли;

Конкурста һәр катнашучының эш нәтиҗәләрен баллар буенча берләштерә һәм бәяли;

Эксперт советы эшчәнлеге максатларына туры килә торган башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

5.3. Конкурсның теоретик һәм практик өлешләре биремнәренең вариантлары Эксперт советы тарафыннан Конкурста катнашучыларга Конкурс башланыр алдыннан гына кәгазьдә килеш җиткерелә.

5.4. Теоретик өлешне бәяләү критерийлары әзерләнгән тест сорауларына җавапларның дөреслегеннән һәм тулылыгыннан гыйбарәт.

Һөнәри эшчәнлек төренә карап, практик биремне бәяләү критерийлары Конкурста катнашучыларның хезмәтне саклау таләпләрен, куркынычсызлык техникасын, һөнәри стандартны, эш процессын оештыру дәрәҗәсен, алдынгы хезмәт алымнарын һәм ысулларын белүләрен, теоретик белемнәрне куллануларын бәяләүне күздә тота.

5.5. Эксперт советы биремнәрне балл системасы буенча бәяли.

5.6. Теоретик өлешнең һәр дөрес җавабы өчен - 1 балл.

Практик өлешне бәяләүнең һәр критерие өчен - 10 баллга кадәр:

хезмәтне саклау, куркынычсызлык техникасы таләпләрен үтәү (0-10 балл);

һөнәри стандартны үтәү (0-10 балл);

эш процессын оештыру дәрәҗәсе (0-10 балл);

алдынгы хезмәт алымнарын һәм ысулларын белү (0-10 балл);

теоретик белемнәрне куллану (0-10 балл).

Билгеләнгән вакыт нормативында (60 минут) теоретик биремне үтәгән өчен максималь балл - 50 балл.

Билгеләнгән вакыт нормативында (30 минут) практик биремне үтәгән өчен максималь балл - 50 балл.

5.7. Биремнәрнең практик өлешен үтәгәндә Эксперт советы түбәндәгеләр өчен штраф балларын куллана ала:

куркынычсызлык техникасы кагыйдәләрен бозган өчен;

бирелгән вакытны арттырган өчен;

хезмәтне дөрес оештырмаган һәм технологик кимчелекләр өчен;

биремнәрне үтәгән вакытта тәртип бозган өчен (бер-берсе белән сөйләшүләр, астыртын әйтүләр, экспертлар белән бәхәсләр һ.б.). Биремнәрне үтәгән вакытта кабат тәртип бозган өчен катнашучы практик биремнәрне үтәүдән читләштерелә.

Һәр бозу өчен - 5 штраф баллы. Практик өлештәге биремнәрне бәяләгәндә штраф баллары бирем өчен катнашучы җыйган балларның гомуми суммасыннан алына.

5.8. Эксперт бәяләү нәтиҗәләре белән шәхсән (турыдан-туры яисә читләтеп) кызыксына, дип уйларга нигез бирә торган хәлләр булса, экспертлар катнашучыларның Конкурс биремнәрен үтәүләрен бәяләргә хокуклы була алмый. Мондый хәлләр барлыкка килү турында экспертлар кичекмәстән Оештыру комитетына хәбәр итәргә тиеш.

5.9. Конкурста һәр катнашучыга әлеге Нигезләмәгә 1нче һәм 2нче кушымталар нигезендәге форма буенча Эксперт советы тарафыннан бәяләү кәгазе тутырыла.

5.10. Теоретик белемнәрне тикшерү һәм практик өлешне үтәү нәтиҗәләре нигезендә әлеге Нигезләмәгә 3нче кушымтадагы форма буенча Эксперт советы тарафыннан җыелма бәяләү ведомосте тутырыла, ул Конкурс этабы тәмамланган көннән алып ике эш көненнән дә соңга калмыйча Оештыру комитетына тапшырыла.

5.11. Оештыру комитеты әлеге Нигезләмәнең 5.10 пунктында күрсәтелгән җыелма бәяләү ведомосте нигезендә Конкурсның җиңүчеләре һәм призерлары турында карар кабул итә, әлеге Нигезләмәгә 4нче кушымта нигезендәге форма буенча Конкурс беркетмәсен раслый.

## VI. Конкурска йомгаклар ясау

6.1. Конкурсның һәр номинациясе буенча җиңүчеләр һәм призерлар билгеләнә. Конкурста җиңүчеләр өчен һәр номинациядә – бер беренче урын, призерлар өчен һәр номинациядә бер икенче урын һәм бер өченче урын карала.

6.2. Конкурсның теоретик һәм практик өлешләре нәтиҗәләре буенча иң күп балл җыйган катнашучылар Конкурс номинацияләрендә җиңүчеләр дип таныла.

Җыелган баллар саны буенча икенче һәм өченче урыннарны алган катнашучылар Конкурс призерлары дип таныла.

6.3. Баллар тигез булган очракта, Конкурста җиңүчеләр һәм призерлар Оештыру комитеты тарафыннан тавыш бирү юлы белән билгеләнә, тавышлар тигез булганда, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

6.4. Конкурста җиңүчеләр һәм призерлар түбәндәге тәртиптә бүләкләнәләр:

1 урын – 50 000 сум акчалата приз (I дәрәҗә диплом);

2 урын – 40 000 сум акчалата приз (II дәрәҗә диплом);

3 урын – 30 000 сум акчалата приз (III дәрәҗә диплом).

200 000 сум күләмендә төп приз - «Гран-при» барлык номинацияләр арасында Конкурсның теоретик һәм практик өлешләрендә иң күп балл җыйган катнашучыга бирелә.

6.5. Конкурста призлы урыннарны алмаган катнашучыларга Конкурста катнашу турында дипломнар һәм 5 000 сум күләмендә акчалата кызыксындыру призы тапшырыла.

6.6. Конкурс нәтиҗәләре буенча призлы урын алган һәм Конкурста катнашуга кертелгәннән соң «Чит ил йогынтысында булган затларның эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты дип танылган катнашучы диплом һәм акчалата приз белән бүләкләнми.

## VII. Конкурсны финанслау

7.1. Конкурсны финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә кую турында» 2019 елның 5 мартындагы 158 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла.

7.2. Җиңүчеләргә һәм катнашучыларга акчалата призлар Оештыру комитеты карары нигезендә чыгарылган Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының уртак боерыгы нигезендә түләнә.

Татарстан Республикасы
агросәнәгать комплексының
яшь хезмәткәрләре арасында
«Һөнәре буенча иң яхшы»
республика һөнәри осталык
конкурсы турында нигезләмәгә
1нче кушымта

Форма

**Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының яшь хезмәткәрләре арасында «Һөнәре буенча иң яхшы» республика һөнәри осталык конкурсында катнашучыларның теоретик өлештә Конкурс биремнәрен үтәү нәтиҗәләрен бәяләү кәгазе**

Уздыру урыны: ___________________________________________________

Конкурс биремнәрен үтәү датасы: _________________________________

Номинация: ______________________________________________________

| № | Катнашу-чының Ф.И.Ат. ис. | Катнашу-чының эш урыны | Вазыйфасы | Дөрес җаваплар саны | Дөрес булмаган җаваплар саны | Баллар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Эксперт советы әгъзалары:

____________________ (имза) ______________________________ (Ф.И.Ат. ис. (атасының исеме – булганда)

____________________ (имза) ______________________________ (Ф.И.Ат. ис. (атасының исеме – булганда)

____________________ (имза) ______________________________ (Ф.И.Ат. ис. (атасының исеме – булганда)

Татарстан Республикасы
агросәнәгать комплексының
яшь хезмәткәрләре арасында
«Һөнәре буенча иң яхшы»
республика һөнәри осталык
конкурсы турында нигезләмәгә
2нче кушымта

Форма

**Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының яшь хезмәткәрләре арасында «Һөнәре буенча иң яхшы» республика һөнәри осталык конкурсында катнашучыларның практик өлештә Конкурс биремнәрен үтәү нәтиҗәләрен бәяләү кәгазе**

Уздыру урыны: ______________________________________________________

Конкурс биремнәрен үтәү датасы: ________________________________________

Номинация: __________________________________________________________

| № | Катнашучының Ф.И.Ат. ис. | Катнашучының эш урыны | Вазыйфасы | Бирем исеме | Үтәү вакыты | Баллар | Штраф баллары | Баллар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | | |
| 3. | | | | | | | | |
| | | | | БАРЫСЫ: | | | | |

Эксперт советы әгъзалары:

______________________ (имза) ________________________________ (Ф.И.Ат. ис. (атасының исеме – булганда)

______________________ (имза) ________________________________ (Ф.И.Ат. ис. (атасының исеме – булганда)

______________________ (имза) ________________________________ (Ф.И.Ат. ис. (атасының исеме – булганда)

Татарстан Республикасы
агросәнәгать комплексының
яшь хезмәткәрләре арасында
«Һөнәре буенча иң яхшы»
республика һөнәри осталык
конкурсы турында нигезләмәгә
3нче кушымта

Форма

**Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының яшь хезмәткәрләре арасында «Һөнәре буенча иң яхшы» республика һөнәри осталык конкурсында катнашучыларның теоретик һәм практик өлешләрдә Конкурс биремнәрен үтәү нәтиҗәләрен җыелма бәяләү ведомосте**

| т/с № | Конкурста катнашучының Ф.И.Ат. ис. (атасының исеме – булганда) | Номинация | Җыелган баллар | | Балларның җыелма суммасы | Бирелгән урын |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | теоретик өлеш | практик өлеш | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Эксперт советы әгъзалары:

__________________ (имза) __________________________ (Ф.И.Ат. ис. (атасының исеме – булганда)

__________________ (имза) __________________________ (Ф.И.Ат. ис. (атасының исеме – булганда)

__________________ (имза) __________________________ (Ф.И.Ат. ис. (атасының исеме – булганда)

Татарстан Республикасы
агросәнәгать комплексының
яшь хезмәткәрләре арасында
«Һөнәре буенча иң яхшы»
республика һөнәри осталык
конкурсы турында нигезләмәгә
4нче кушымта

Форма

**Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының**
**яшь хезмәткәрләре арасында**
**«Һөнәре буенча иң яхшы»**
**республика һөнәри осталык конкурсына**
**йомгаклар турында**
**БЕРКЕТМӘ №___**

1.Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының яшь хезмәткәрләре арасында «Һөнәре буенча иң яхшы» республика һөнәри осталык конкурсының Оештыру комитеты (алга таба - Оештыру комитеты) утырышында катнаштылар:

| т/с № | Ф.И.Ат. ис. (атасының исеме – булганда) | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

2. Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының яшь хезмәткәрләре арасында «Һөнәре буенча иң яхшы» республика һөнәри осталык конкурсын (алга таба - Конкурс) үткәрү йомгакларын карау процедурасы 20__ елның «___» ___________ ________________________________________________ узды.

(уздыру урынын күрсәтергә)

3. Конкурс уздыру йомгакларын карау өчен Оештыру комитетына Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының яшь хезмәткәрләре арасында «Һөнәре буенча иң яхшы» республика һөнәри осталык конкурсында катнашучыларның теоретик һәм практик өлешләрдә Конкурс биремнәрен үтәү нәтиҗәләрен бәяләү кәгазьләре һәм Конкурс биремнәрен үтәү нәтиҗәләрен җыелма бәяләү ведомосте тапшырыла, алар Эксперт советы әгъзалары тарафыннан имзаланган булырга тиеш.

4. Оештыру комитеты Конкурста катнашучыларның Конкурс биремнәрен үтәү йомгакларын карады һәм Конкурсның җиңүчеләре һәм призерлары турында түбәндәге карарны кабул итте:

| т/с № | Конкурста катнашучының Ф.И.Ат. ис. (атасының исеме – булганда) | Оешма исеме, вазыйфасы | Номинация | Бирелгән урын |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Оештыру комитеты рәисе: ______________________ ______________________

(имза) имзаның расшифровкасы